ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30 октябрь, 2024 ел № 37/6

Физик затлар мөлкәтенә салым турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2, 403 статьялары, «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлек территориясендә түләү мәҗбүри булган физик затлар мөлкәтенә салым билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Салым ставкаларын түбәндәге күләмдә билгеләргә:

1) 0,1 процент:

- гаражлар һәм машина кую урыннарынарына, шул исәптән әлеге Карарның 2 пунктының 4, 5, 6 пунктчаларында күрсәтелгән салым салына торган объектларда урнашканнарына карата;

- һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык яисә шәхси торак төзелеше алып бару өчен җир участокларында урнашкан хуҗалык корылмалары яисә төзелмәләргә карата;

2) 0,2 процент:

- фатирлар, фатир өлешләре, бүлмәләргә карата;

3) 0,3 процент:

- торак йортлар, торак биналарның өлешләренә карата;

- объектларның проект билгеләнеше торак бинасы булган тәмамланмаган төзелеш объектларына карата;

- ким дигәндә бер торак бинаны үз эченә алган бердәм күчемсез милек комплексларына карата;

4) Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнүче исемлеккә кертелгән гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан 2000 квадрат метрга кадәр булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы биналарга һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган

салым салу объектларына карата көчеш чорындагы 2025-2027 елларда 1,2 процент, 2028 елда һәм аннан соңгы елларда 2,0 процент;

5) Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнүче исемлеккә кертелгән һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата 2,0 процент, әлеге Карарның 2 пункты 4 пунктчасында күрсәтелгән объектлардан тыш;

6) һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата 2026 елда 2,0 процент, аннан соңгы елларда – 2,5 процент;

7) башка салым салу объектларына карата 0,5 процент.

3. Ике фатирдан торган бер катлы күпфатирлы торак йортта торак милекчеләренә исәпләнгән салым суммасын әлеге фатирның гомуми мәйданының 30 квадрат метрының кадастр бәясендә салым ставкасының процент өлеше буларак билгеләнә торган суммага киметү рәвешендә ташлама бирергә.

Әгәр гомуми өлешле милектә булса, ташлама суммасы өлешле милектә катнашучыларның һәркайсы өчен әлеге фатирга милек хокукындагы өлешенә пропорциональ рәвештә исәпләнә.

Әгәр дә фатир уртак гомуми милектә булса, ташлама күләме уртак милекчеләрнең һәрберсенә тигез өлештә исәпләнә.

Бу очракта, әлеге пункт нигезендә исәпләнгән ташлама күләме, ташламасыз исәпләнгән салым күләменнән артык була алмый.

4. Физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән азат итәргә:

1) 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк баласы булган салым түләүчеләрне (ата-аналар, уллыкка (кызлыкка) бала алган ата-аналар), опекуннар һәм попечительләр (тәрбиягә бала алган, патронат ата-аналар));».

2) әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән салым түләүчеләрнең балаларын.

Салым ташламалары түбәндәге төр салым салу объектларына карата бирелә:

1) фатир, фатир яки бүлмә өлеше, торак йорт яки торак йорт өлеше;

2) мәйданы 30 квадрат метрдан артмаган гараж яки машина кую урыны, шул исәптән бу карарның 2 пунктының 4, 5, 6 пунктчаларында күрсәтелгән салым салу объектларында урнашканнарын да кертеп.

Салым ташламасы, салым ташламаларын куллану өчен нигезләр санына бәйсез рәвештә, гаиләгә туры килә торган һәр салым салу объекты төренә кергән бер объектка карата салым түләүченең теләге белән бирелә.

Салым ташламасы яшәү урыны буенча теркәлү урыны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге булган салым түләүчеләргә салым түләүче милкендә булган һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган салым объектына карата салым суммасы күләмендә бирелә.

Салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым ташламалары хокукына ия физик затлар салым органына үз теләге белән салым ташламасын бирү турында гариза тапшыра, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документлар тапшырырга хокуклы.

Салым ташламасы өчен сайланган салым салу объектлары турында белдерү салым түләүченең үз теләге белән салым органына әлеге объектларга карата салым

ташламасы кулланыла торган салым чоры булып торучы елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча тапшырыла.

5. Көчен югалткан дип танырга:

1) Шәһәр Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 22 октябрендәге 2/11 номерлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының ноябрендәге 81, «Шәһри Чаллы» газетасының 2015 елның 28 октябрендәге 79 саннарында басылган;

2) «Шәһәр Советының 2015 елның 22 октябрендәге «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2/11 санлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 15 декабрендәге 21/8 номерлы Шәһәр Советы Карарын, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru 26.12.2017, «Челнинские известия» газетасының 2017 елның 27 декабрендәге 97, «Шәһри Чаллы» газетасының 2018 елның 2 гыйнварындагы 2 саннарында басылган;

3) «Шәһәр Советының 2015 елның 22 октябрендәге «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2/11 санлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 8 ноябрендәге 27/7 номерлы Шәһәр Советы Карарын, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru 14.11.2018, «Челнинские известия» газетасының 2018 елның 14 ноябрендәге 82, «Шәһри Чаллы» газетасының 2018 елның 14 ноябрендәге 82 саннарында басылган;

4) «Шәһәр Советының 2015 елның 22 октябрендәге «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2/11 санлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 7 октябрендәге 33/7 номерлы Шәһәр Советы Карарын, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru 11.10.2019, «Челнинские известия» газетасының 2019 елның 11 октябрендәге 75, «Шәһри Чаллы» газетасының 2019 елның 18 октябрендәге 77 саннарында басылган;

5) «Шәһәр Советының 2015 елның 22 октябрендәге «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2/11 санлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 6 декабрендәге 34/8 номерлы Шәһәр Советы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2019 елның 11 декабрендәге 91, «Шәһри Чаллы» газетасының 2019 елның 13 декабрендәге 92 саннарында басылган;

6) «Шәһәр Советының 2015 елның 22 октябрендәге «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2/11 санлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 21 февралендәге 37/7 номерлы Шәһәр Советы Карарын, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru 28.02.2020, «Челнинские известия» газетасының 2020 елның 28 февралендәге 15, «Шәһри Чаллы» газетасының 2020 елның 28 февралендәге 15 саннарында басылган;

7) «Шәһәр Советының 2015 елның 22 октябрендәге «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2/11 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 27 маендагы 7/5 номерлы Шәһәр Советы Карарын, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru 28.05.2021, «Челнинские известия» газетасының 2021 елның 28 маендагы 38, «Шәһри Чаллы» газетасының 2021 елның 28 маендагы 38 саннарында басылган;

8) «Шәһәр Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 2 ноябрендәге 17/7 номерлы Шәһәр Советы Карарының 2 пунктын, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru

15.11.2022, «Челнинские известия» газетасының 2022 елның 15 ноябрендәге 82, «Шәһри Чаллы» газетасының 2022 елның 15 ноябрендәге 82 саннарында басылган;

9) «Шәһәр Советының җирле салымнар турында аерым Карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 28 декабрендәге 29/5 номерлы Шәһәр Советы Карарын, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru 17.01.2024, «Челнинские известия» газетасының 2024 елның 10 гыйнварындагы 1, «Шәһри Чаллы» газетасының 2024 елның 12 гыйнварындагы 2 саннарында басылган;

10) «Шәһәр Советының 2015 елның 22 октябрендәге «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2/11 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 7 августындагы 35/11 номерлы Шәһәр Советы Карарын, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru 20.08.2024 басылган.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

7. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев